**ГЛАВА КАЗАКЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422722, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Казаклар, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЗАКЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Казаклар авылы, Совет ур.,5

Тел./факс: +7(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07 ноябрь, 2022 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар, Өлә торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 31 октябрендәге 125 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары (Советның 15.05.2020 №142, 22.12.2020 № 20 карарлары редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2022 елның 19 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар торак пунктында Казаклар мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча: Өлә авылы, Совет урамы, 11 йорт;

1.2. 2022 елның 19 ноябрендә 15.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Өлә торак пунктында мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча: Өлә авылы, Совет урамы, 11 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Казаклар торак пунктында: «2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Казаклар торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Өлә торак пунктында: «2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлегенең Өлә торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" интернет-телекоммуникация челтәрендәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Казаклар авыл җирлеге
башлыгының Р.Р.Сафин